КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 26 февраль г.Казань № 97

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында махсус сакланаыла торган табигать территорияләре дәүләт реестрын раслау һәм махсус сакланыла торган табигать территорияләре мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 ел, 24 июль, 520 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында махсус сакланыла торган табигать территорияләре дәүләт реестрын раслау һәм махсус сакланыла торган табигать территорияләре мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 ел, 24 июль, 520 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 24 март, 192 нче; 2011 ел, 13 май, 393 нче; 2011 ел, 26 июль, 604 нче; 2011 ел, 8 август, 641 нче; 2012 ел, 17 июль, 600 нче; 2013 ел, 27 март, 208 нче; 2013 ел, 1 июнь, 374 нче; 2013 ел, 6 июнь, 390 нчы; 2014 ел, 20 май, 335 нче; 2014 ел, 11 июнь, 399 нчы; 2014 ел, 17 октябрь, 767 нче; 2014 ел, 24 ноябрь, 904 нче; 2016 ел, 11 июль, 475 нче; 2016 ел, 21 июль, 493 нче; 2017 ел, 31 гыйнвар, 42 нче; 2017 ел, 30 сентябрь, 744 нче; 2018 ел, 12 февраль, 76 нчы; 2018 ел, 21 май, 380 нче; 2019 ел, 26 март, 221 нче; 2019 ел, 28 май, 445 нче; 2020 ел, 5 февраль, 77 нче; 2020 ел, 6 октябрь, 909 нчы; 2020 ел, 4 ноябрь, 994 нче; 2022 ел, 28 февраль, 183 нче; 2022 ел, 16 июнь, 569 нчы; 2022 ел, 18 август, 853 нче; 2022 ел, 2 сентябрь, 953 нче; 2022 ел, 26 октябрь, 1144 нче; 2022 ел, 2 декабрь, 1277 нче; 2023 ел, 18 февраль, 152 нче; 2023 ел, 24 март, 344 нче; 2023 ел, 13 ноябрь, 1472 нче; 2023 ел, 29 декабрь, 1756 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге

үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «махсус сакланыла торган табигать территорияләре мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында махсус сакланыла торган табигать территорияләре дәүләт реестрында:

«Икенче басма» һәм «Редакция коллегиясе» бүлекләре үз көчен югалткан дип танырга;

«Аңлатма язуы» бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында
аерым саклана торган табигать территорияләре

Республиканың табигать-тыюлык фонды 465,139 мең гектар гомуми мәйданлы 194 махсус сакланыла торган табигать территорияләрен тәшкил итә, бу – Татарстан Республикасының гомуми мәйданының җиде проценты; монда табигать комплексларын, ландшафтларны һәм биологик төрлелекне саклау һәм торгызу өчен уңай шартлар тәэмин ителде:

федераль әһәмияттәге махсус сакланыла торган табигать территорияләре:

Идел-Кама дәүләт табигать биосфера тыюлыгы;

«Түбән Кама» милли паркы;

«Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең Ботаника бакчасы;

төбәк әһәмиятендәге махсус сакланыла торган табигать территорияләре:

комплекслы (ландшафтлы) һәм биологик (ботаника) юнәлештәге 28 дәүләт табигать тыюлыгы;

биш дәүләт табигать зоология (аучылык) тыюлыклары;

дүрт дәүләт табигать зоология тыюлыгы;

төбәк әһәмиятендәге 149 табигать һәйкәле (30 елга, 33 күл, ике чишмә, 13 су комплексы, 71 җир өсте комплексы);

җирле әһәмияттәге махсус сакланыла торган табигать территорияләре:

«Лебяжье» шәһәр урман паркы;

Казан шәһәренең «Җиңү паркы»;

Казан шәһәренең «М.Горький исемендәге Үзәк мәдәният һәм ял паркы;


«Савиново» паркы» рекреация урыны.

Махсус сакланыла торган һәр табигать территориясе буенча мәгълүматта аның статусы һәм хокукны билгели торган документлары, урнашу урыны һәм махсус сакланыла торган табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы органнар, шулай ук объектның карта-схемасы һәм гомуми тасвирнамәсе бирелә.»;

«Актаныш муниципаль районы» бүлегенең «Агыйдел елгасы дельтасы (208)» бүлекчәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Агыйдел елгасы дельтасы (208)

| | |
|---|---|
| Статусы | Төбәк әһәмиятендәге комплекслы юнәлештәгне дәүләт табигать тыюлыгы |
| Гамәлгә кую документлары | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 31 август, 761 нче карары |
| Урнашу урыны | Татарстан Республикасының Актаныш муниципаль районы |
| Башкарма хакимиятнең - контрольдә тотучы республика органы | Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты |




Объектның тасвирнамәсе һәм аның әһәмияте. Тыюлыкның гомуми мәйданы 14 982,79 гектар тәшкил итә.

Тыюлык Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән табигать комплексларын саклау, үсемлекләрнең һәм хайваннарның су һәм су тирәли төрләрен

саклау зарурлыгына нигезләнеп оештырылган.

Тыюлык территориясе картайган күлләрне, сазлык массивларын, кара зирекле урманнарны, су баса торган болыннарны үз эченә алган су-сазлык җирләреннән тора.

Әлеге территориядә үсемлекләрнең һәм хайваннарның, шул исәптән Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгәннәрнең төрләре, ягъни үсемлекләрдән ак төнбоек, сазлык кырлы борчагы, сазлык йод үләне, ике яфраклы төнге миләүшә үсә; хайваннардан ысылдавык аккош, яр чыпчыгы, соры торна, ак койрыклы диңгез бөркете яши.

Саклау чаралары. Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тыюлыкны саклау режимы нигезендә.»;

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин